КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 декабрь г.Казань № 1205

2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күрсәтелгән муниципаль берәмлек территориясендә күргәзмә чараларын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Kарарга теркәлгән 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күрсәтелгән муниципаль берәмлек территориясендә күргәзмә чараларын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 декабрь, 1205 нче
карары белән расланды

2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күрсәтелгән муниципаль берәмлек территориясендә күргәзмә чараларын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге (алга таба - муниципаль берәмлек) бюджетына күрсәтелгән муниципаль берәмлек территориясендә күргәзмә чараларын оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар (алга таба - башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Башка бюджетара трансфертлар 2020 елда Министрлыкка бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнар юнәлешләре түбәндәгеләр була:

күргәзмә чараларын әзерләү һәм уздыру, катнашучыларны җыю өчен җәлеп ителә торган белгечләрнең хезмәте өчен түләү;

басма һәм типография хезмәтләре күрсәтү;

басма һәм типография продукциясен монтажлау/демонтаж, урнаштыру эшләре;

реклама;

күргәзмә чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле техник чараларны һәм ярдәмче җиһазларны арендалау, сатып алу;

махсуслаштырылган күргәзмә павильоны арендасы;

каты коммуналь калдыкларны чыгару.

4. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

гамәлгә ашыру максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган күргәзмә чаралары исемлеген раслый торган муниципаль берәмлекнең хокукый акты булу;

муниципаль берәмлектә экспозиция мәйданчыгы булу;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә финанслар белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган бюджет ассигнованиеләре булу.

6. Муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү

Министрлык һәм муниципаль берәмлек башкарма комитеты арасында төзелә торган Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла, анда түбәндәгеләр каралган:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертның күләме;

муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшереп тору тәртибе;

башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең мәгънәсе;

финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе, рәвеше һәм сроклары һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечен үтәү;

Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүләрне гамәлгә ашыру хокукы;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән шартлар бозылган очракта Килешүне өзү тәртибе;

якларның җаваплылыгы.

Килешү Министрлык тарафыннан раслана торган форма нигезендә төзелә.

7. Муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль берәмлек башкарма комитеты Министрлыкка түбәндәге тәртиптә таныкланган документларны кушып, башка бюджетара трансфертлар бирү турында ирекле рәвештә гариза (алга таба - гариза) тапшыра:

вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган чаралар исемлеген тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган 2020 елга муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының кабул ителгән карарыннан өземтә;

муниципаль берәмлек җирле үзидарә органының күргәзмә чараларының календарь планын раслый торган муниципаль хокукый акты, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешендә күргәзмә чаралары тематикасының ролен, күргәзмә чараларының максатларын һәм бурычларын, күргәзмә чаралары дәрәҗәсен (халыкара, гомумроссия, төбәкара, республика, җирле әһәмияттәге) күрсәтеп;

күргәзмә экспозициясенең күргәзмә чараларына багышланган дизайн-проекты (булган очракта) фотоматериаллар, видео- һәм медиаматериаллар, шулай ук күргәзмә чаралары буенча презентация материаллары;

шушы күргәзмә чараларында катнашучы оешмаларның саны турында белешмәләр;

күргәзмә чараларын үткәрү өчен экспозиция мәйданчыгы турында белешмәләр.

8. Муниципаль берәмлек башкарма комитетыннан кергән документлар Министрлык тарафыннан шушы документларны терк әгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә карала. Документлар Министрлык тарафыннан алар кергән көнне терк әлә.

Әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган (тулы күләмдә тапшырмаган) яисә тапшырылган документлар, алардагы белешмәләр әлеге Тәртиптә каралган шартларга туры килмәгән очракта, шулай ук муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмаган очракта, Министрлык гаризаны кире кага һәм гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көннән дә соңга калмыйча, кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп, муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына мөрәҗәгать итә.

Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәгән очракта, гаризаны кире кагу турында хәбәр алынган көннән соң 10 көн эчендә кабат гариза бирергә хокуклы.

Муниципаль берәмлек башкарма комитетының кабат заявкаларын карау тәртибе беренче тапкыр бирелгән гаризаларны карау тәртибенә тәңгәл килә.

9. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасы белән операцияне исәпкә алу өчен ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнары счетларына күчерелә.

10. Муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме (C) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C = S \times 17\,233{,}34 \text{ сум},$$

монда:

S - күргәзмә чараларын үткәрү өчен бүлеп бирелгән экспозиция мәйданчыгы мәйданы;

17 233,34 сум - экспозиция мәйданчыгының 1 кв.метрына чыгымнарның иң чик күләме.

Муниципаль берәмлеккә бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган бюджет ассигнованиеләреннән һәм бюджет йөкләмәләре лимитларыннан арта алмый.

11. Башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелеген бәяләү башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелек күрсәткече нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелек күрсәткече булып муниципаль берәмлек тарафыннан календарь план буенча үткәрелә торган күргәзмә чараларында катнаша торган оешмалар саны (кимендә 30) тора.

13. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты Министрлыкка электрон рәвештә һәм кәгазь чыганакта Килешүдә каралган срокларда һәм формада башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечен үтәү турында хисап тапшырырга тиеш.

14. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты һәм аның вазыйфаи затлары тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара

трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

15. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты 2020 елның 31 декабренә торышы буенча Килешүдә каралган йөкләмәләрне бозуга дучар булган һәм 2021 елның 5 апреленә кадәр күрсәтелгән хокук бозулар бетерелмәгән очракта, муниципаль берәмлек бюджетыннан 2021 елның 15 маена кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиешле акчалар күләме ($V_{кайтару}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{кайтару} = (C_i \times D) \times 0{,}1,$$

монда:

$C_i$ – хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләме;

D – башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты.

16. Башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты (D) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T - хисап датасына башка бюджетара трансфертны файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткеченең фактта ирешелгән кыйммәте;

S – килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең пландагы әһәмияте.

17. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмаган һәм (яисә) муниципаль берәмлек башкарма комитеты аны бирү шартларын бозган очракта, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акчалар кире алынмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүриләү бюджет чаралары кулланыла.

18. 2021 елның 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2021 елның беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Министрлык билгеләгән тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә алынырга тиеш.

19. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

20. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Министрлык тарафыннан башкарыла.____________